Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында" Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына һәм "Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең жирле үзидарә органнарына сәламәтлек саклау олкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2009 елның 3 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында" 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш), № 12 (III өлеш); 2005, № 2; 2006, № 2 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 5 (I өлеш), № 12 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 нчы пункттагы икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән тәэмин итү, шул исәптән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана торган авырулар исемлегенә кертелгән авыру булганда – түләүсез;";

2) 7 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итү." .

**2 статья**

"Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына сәламәтлек саклау өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында" 2006 елның 16 мартындагы 19-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 3 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән тәэмин итүне оештыру." ;

2) 5 статьяның 4 нче өлешендәге "ике яшькә кадәрге балаларны балалар туклануының махсус продуктлары белән тәэмин итү буенча" сүзләрен "өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән тәэмин итү буенча" сүзләренә алмаштырырга;

3) 10 статьядагы 1 нче өлешнең 1 пунктында һәм 3 нче өлештә "ике яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча балалар туклануының махсус продуктлары белән тәэмин итүне оештыру" сүзләрен "өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән тәэмин итүне оештыру" сүзләренә алмаштырырга;

4) 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына сәламәтлек саклау өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында" Татарстан Республикасы Законына 2 нче кушымта

**Өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен башкаруга компенсацияләрнең төбәк фондыннан җирле бюджетларга бирелә торган субвенцияләр күләмен билгеләү өчен нормативларны исәпләп чыгару**
**МЕТОДИКАСЫ**

1. Өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен башкаруга компенсацияләрнең төбәк фондыннан җирле бюджетларга бирелә торган субвенцияләр күләмен билгеләү өчен нормативларны исәпләп чыгару методикасы Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә әзерләнде.

2. Өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән тәэмин итүгә муниципаль берәмлек бюджетына бирелә торган субвенцияләр күләме түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$S_i = \sum_{a=1}^{n} H_{i1_a} \times N_{i1_a} + \sum_{b=1}^{m}\sum_{c=1}^{o} H_{i2_{bc}} \times N_{i2_{bc}} + \sum_{d=1}^{k} H_{i3_d} \times N_{i3_d} + R,$$

монда:

$S_i$ - өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән тәэмин итүгә i-муниципаль берәмлегә өчен субвенция күләме;

$H_{i1_a}$ – җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән кимрәк булган гаиләләрдә яшәүче, табиблар рецептлары буенча махсус сөт продуктларын һәм катнашмаларын алучы өч яшькә кадәрге балалар саны;

$N_{1_a}$ – җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән кимрәк булган гаиләдә яшәүче баланы табиблар рецептлары буенча махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән тәэмин итүгә финанс чыгымнары нормативы;

$H_{i2_{bc}}$ – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана торган исемлектәге авыруы булган, табиблар рецептлары буенча махсус сөт продуктларын һәм катнашмаларын алучы өч яшькә кадәрге балалар саны;

$N_{2_{bc}}$ – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана торган исемлектәге авыруы булган баланы табиблар рецептлары буенча махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән тәэмин итүгә финанс чыгымнары нормативы;

$H_{i3_d}$ – табиблар рецептлары буенча махсус сөт продуктларын һәм катнашмаларын ике яшькә җиткәнче алу хокукын саклап калган ике яшькә кадәрге балалар саны;

$N_{3_d}$ – табиблар рецептлары буенча махсус сөт продуктларын һәм катнашмаларын ике яшькә җиткәнче алу хокукын саклап калган баланы тәэмин итүгә финанс чыгымнары нормативы;

R – чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган бүленмәгән резервтан әлеге Методика нигезендә i-муниципаль берәмлегенә Татарстан Республикасы бюджеты акчаларының баш бүлүчесе тарафыннан бүлеп бирелә торган акчалар;

a, b, d – баланың яшь категориясе;

c – балаларның Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана торган исемлектәге авырулары;

n, m, k – балаларның яшь категорияләре саны;

o – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана торган авырулар исемлегендәге авырулар саны.

3. Җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән кимрәк булган гаиләләрдә яшәүче балаларны, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана торган исемлектәге авыруы булган балаларны табиблар рецептлары буенча махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән тәэмин итүгә финанс чыгымнары нормативлары ел саен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана." .

**3 статья**

1. Әлеге Закон 2010 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
2. Әлеге Закон үз көченә кергәнче ике яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итү рәвешендәге социаль ярдәм чарасы күрсәтелгән гражданнарга карата әлеге Законның 1 статьясы нигезләмәләре кулланылмый.

Татарстан Республикасы
Президенты

М.Ш. Шәймиев

Казан, Кремль
2009 елның 22 декабре
№ 67-ТРЗ